ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.03.2019 ел Баулы шәһәре №70

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 21 июнендә кабул ителгән 61нче номерлы карары белән расланган Баулы муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару тәртибенә өстәмәләр кертү турында

2018 елның 11 апрелендә кабул ителгән «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»гы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 21 июнендә кабул ителгән 61нче номерлы карары белән расланган Баулы муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару тәртибенә түбәндәге өстәмәләр кертергә:

1.3. пунктта «даими рәвештә пассажирлар йөртү» сүзләреннән соң «(индивидуаль эшмәкәрнең яшәү урыны турындагы мәгълүматтан тыш)» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче И.И. Гозәеров